

0+

Резеда Шәрипова

# Сабантуй

Татарстан китап нәшрияты

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ш 95

Рәссамы *Илдус Әҗемов*

**Шәрипова, Р. С.**

Ш95 Сабантуй : балалар өчен шигырьләр / Резеда Шәрипова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2018. – 15 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-03600-9

Татар халкының яраткан бәйрәменең тәртибен хәтерлисезме әле? Балалар Сабантуйны ничек итеп күрә? Чын Сабан туе нинди булырга тиеш? Бу сорауларга җавапларны әлеге китаптан таба аласыз.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03600-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2018
© Шәрипова Р. С., 2018



## БӘЙРӘМ ТАҢЫ

Борыннарны кытыклап
Уятты коймак исе,
Самаварда кояш көлә –
Өйдә чын бәйрәм төсе!

Таң белән үк торып, әти
Мунча ягып өлгергән.
Ишегалдын, капка төбен
Ялт иттереп себергән.

Кунаклар килгәнче, мин дә
Торып урынны җыйдым.
Чәчемне тарап, өр-яңа
Күлмәкне киеп куйдым.

Үтми дә үтми һич вакыт,
Ничек түзеп торасы,
Әллә инде сәгать угын
Алга таба борасы?

Сизми дә калды өлкәннәр –
Күчердем куйдым укны.
Бәйрәм көнне гаеп түгел,
Гафу ителә шуклык.

«Башлана!» дип торып чаптым
Малай-кызлар янына –
Сабантуй гөрләп узачак
Әрәмә аланына.



## Ә ӘРӘМӘДӘ...

Мин генә ашыкмыйм икән,
Бала-чага күп монда.
Сәйлән итеп тезелдек без
Сабантуй мәйданында.

Аллы-гөлле күлмәкләрдән
Күзләрең камашырлык,
Болын чәчәкләре белән
Төсләрдә ярышырлык!

Мактанышып туйгач,
дәррәү
Кибеткә дип йөгердек.
Ярый әле өлкәннәрдән
Алда килеп өлгердек!

Елан кебек бормаланып
Тезелде озын чират.
Куандырды сатучылар
Туңдырма белән сыйлап.



ЭЧТӘЛЕК


Бәйрәм таңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ә әрәмәдә… . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Көрәш башланды! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үзе егылган еламый . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Колга башында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Чүлмәк вату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кашык кабып йөгерү . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Катыктан акча эзләү . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Чабышкылар килә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Капчык сугышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җитез кызлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Булачак чемпион . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аркан тартышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Һәр тарафта уен-моң! . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бәйрәмнән соң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .


